| Республика Татарстан<br><br>Исполнительный комитет<br>Менделеевского<br>муниципального района | | Татарстан Республикасы<br><br>Менделеевск муниципаль<br>районы<br>башкарма комитеты |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.04.2022 ел Менделеевск ш. №292

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү проектын
әзерләү турында

Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерү мәсьәләләрен җайга салу максатларында, Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

К А Р А Р  И Т Ә:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2022 елның 30 мартындагы 112 номерлы карары белән расланган Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга: www.mendeleevsk.tatar.ru.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.И.Беляев

Килештерелде:
Хокук бүлеге башлыгы Е.С.Царева